КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 24 гыйнвар г.Казань № 34

Девиант тәртипле белем алучылар өчен ябык типтагы «Н.А.Галләмов исемендәге Республика махсус гомуми белем бирү мәктәбе» дәүләт казна махсус уку-укыту-тәрбия гомуми белем бирү учреждениесе исемен үзгәртү турында

«Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законга, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 22 һәм 66 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында һәм РСФСРның һәм Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актлары (закон чыгару актлары нигезләмәләре) үз көчен югалткан дип санау турында» 2018 елның 27 июнендәге ФЗ-170 номерлы Федераль законның 4 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Девиант тәртипле белем алучылар өчен ябык типтагы «Н.А.Галләмов исемендәге Республика махсус гомуми белем бирү мәктәбе» дәүләт казна махсус уку-укыту-тәрбия гомуми белем бирү учреждениесе исемен «Н.А.Галләмов исемендәге Республика махсус гомуми белем бирү мәктәбе» ябык типтагы дәүләт казна махсус уку-укыту-тәрбия гомуми белем бирү учреждениесе (алга таба – Учреждение) дип үзгәртү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына 60 көн эчендә Девиант тәртипле белем алучылар өчен ябык типтагы «Н.А.Галләмов исемендәге Республика махсус гомуми белем бирү мәктәбе» дәүләт казна махсус уку-укыту-тәрбия гомуми белем бирү учреждениесе уставына һәм Девиант тәртипле белем алучылар өчен ябык типтагы «Н.А.Галләмов исемендәге Республика махсус гомуми белем бирү мәктәбе» дәүләт казна махсус уку-укыту-тәрбия гомуми белем бирү учреждениесе өчен гамәлгә куючының дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсенә тиешле үзгәрешләрне кертергә.

3. Дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин